КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1201

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авария, табигый һәм техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр булган очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 12 октябрь, 787 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 27 ноябрь, 910 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1301 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Авария, табигый һәм техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр булган очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авария, табигый һәм техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр булган очракта, күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә зыян килүне (гомуми мөлкәт җимерелүне) раслый торган, җирле үзидарә органы вәкилләре, күпфатирлы йорт белән идарә итүне яки хезмәтләр күрсәтүне һәм (яки) күпфатирлы йортны тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаруны гамәлгә ашыручы зат һәм (яки) күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре вәкиле тарафыннан кул куелган күпфатирлы йортны комиссия тикшерүе акты күчермәсе;»;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә капиталь ремонт фондын формалаштыру ысуллары турында, капиталь ремонт фондын форма-

лаштыру ысулын сайлау тәртибе турында хәбәр итү тәртибен һәм Күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләренә һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасының эчтәлеге һәм капиталь ремонт үткәрү чираты билгеләнә торган күпфатирлы йортларның торышын бәяләү критерийлары турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында» 2018 ел, 22 август, 692 нче карары белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә капиталь ремонт фондын формалаштыру ысуллары турында, капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау тәртибе турында хәбәр итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

икенче абзацта татар текстында «рәсми сайтында» сүзләреннән соң «һәм массакүләм мәгълүмат чараларында» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «җәбәрә» сүзе алдына «почта элемтәсе аша» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «җәбәрә» сүзе алдына «почта элемтәсе аша» сүзләрен өстәргә;

4 пунктның беренче абзацында «җәбәрә» сүзе алдына «почта элемтәсе аша» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин